**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президентының «Шәһәрдә уңайлы мохит булдыру» өстенлекле проектын гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча республика ведомствоара комиссиясе турында» Указына үзгәрешләр кертү турында

«Шәһәрдә уңайлы мохит булдыру» өстенлекле проектын гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча республика ведомствоара комиссиясе эшчәнлеген камилләштерү максатында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Шәһәрдә уңайлы мохит булдыру» өстенлекле проектын гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча республика ведомствоара комиссиясе турында» 2017 елның 29 маендагы ПУ-448 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 14 мартындагы ПУ-231 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Указда:

атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шәһәрдә уңайлы мохит булдыру» федераль проекты чараларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе турында»;

преамбулада «өстенлекле проектын гамәлгә ашыруны» сүзләрен «федераль проект чараларын гамәлгә ашыруны» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «өстенлекле проектын гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча республика ведомствоара комиссиясен» сүзләрен «федераль проект чараларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясен» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «өстенлекле проектын гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча республика ведомствоара комиссиясе» сүзләрен «федераль проект чараларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктның икенче абзацында «өстенлекле проектын гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча республика ведомствоара комиссиясе» сүзләрен «федераль проект чараларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

б) «Шәһәрдә уңайлы мохит булдыру» өстенлекле проектын гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча республика ведомствоара комиссиясе турында нигезләмәдә:

атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шәһәрдә уңайлы мохит булдыру» федераль проекты чараларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе турында нигезләмә»;

1 пунктта:

«өстенлекле проектын гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча республика ведомствоара комиссиясе» сүзләрен «федераль проекты чараларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

«өстенлекле проектын үтәүнең» сүзләрен «федераль проектын үтәүнең» сүзләренә алмаштырырга;

«(алга таба – Өстенлекле)» сүзләрен «(алга таба – Федераль)» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта:

«а» пунктчасында «Өстенлекле» сүзен «Федераль» сүзенә алмаштырырга;

«б» пунктчасында «өстенлекле» сүзен «федераль» сүзенә алмаштырырга;

«е» пунктчасында:

«Өстенлекле проектны гамәлгә ашыру барышы турында» сүзләрен «Федераль проект чараларын гамәлгә ашыру барышы турында» сүзләренә алмаштырырга;

«Өстенлекле проект буенча» сүзләрен «Федераль проект буенча» сүзләренә алмаштырырга;

«Өстенлекле проектны гамәлгә ашыру өчен» сүзләрен «Федераль проект чараларын гамәлгә ашыру өчен» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта:

«а» пунктчасында «Өстенлекле» сүзен «Федераль» сүзенә алмаштырырга;

«б» пунктчасында «Өстенлекле» сүзен «Федераль» сүзенә алмаштырырга;

«в» пунктчасында «Өстенлекле проектны гамәлгә ашыру белән бәйле» сүзләрен «Федераль проект чараларын гамәлгә ашыру белән бәйле» сүзләренә алмаштырырга;

«г» пунктчасында «Өстенлекле» сүзен «Федераль» сүзенә алмаштырырга;

5 пунктта:

«в» пунктчасында «Өстенлекле проектны гамәлгә ашыруны» сүзләрен «Федераль проект чараларын гамәлгә ашыруны» сүзләренә алмаштырырга;

«д» пунктчасында «Өстенлекле проектны гамәлгә ашыру белән» сүзләрен «Федераль проект чараларын гамәлгә ашыру белән» сүзләренә алмаштырырга;

в) «Шәһәрдә уңайлы мохит булдыру» өстенлекле проектын гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча республика ведомствоара комиссиясе (алга таба – Комиссия) составында:

атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шәһәрдә уңайлы мохит булдыру» федераль проекты чараларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе составы»;

Комиссия составыннан Ф.С. Габделганиевны, М.А. Корниловны, Р.А. Ратникованы, Л.Р. Сафинны, Р.З. Тимерҗановны, И.Ә. Фәйзуллинны чыгарырга;

Комиссия составына кертергә:

аны Комиссия рәисе урынбасары итеп раслап, Айзатуллин Марат Мансур улын – Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрын;

Демидов Виктор Николаевичны – Татарстан Республикасы буенча баш федераль инспекторны (килешү буенча);

Медведев Андрей Ростиславовичны – «РОССИЯ ЯКЛЫ» ХАЛЫК ФРОНТЫ» гомумроссия иҗтимагый хәрәкәтенең Татарстан Республикасында шәһәрдә уңайлы мохит булдыруны мониторинглау үзәге төбәк координаторын (килешү буенча);

Сәмигуллин Марат Тәлгать улын – «БЕРДӘМ РОССИЯ» бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстан төбәк бүлекчәсе Төбәк башкарма комитеты җитәкчесен (килешү буенча);

Сибгатуллин Илдар Нурзадә улын – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсе башлыгын;

Хәнифов Фәрит Мөдәррис улын – Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрын;

Шаһиәхмәтов Мидхәт Рәфкать улын – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарын – Татарстан Республикасы икътисад министрын;

Комиссия әгъзалары вазыйфаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Р.Ш. Ганибаевның – «Бөтенроссия инвалидлар җәмгыятенең Татарстан республика оешмасы» – «Татарстан Республикасы инвалидлар җәмгыяте» иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча)»;

Ә.С. Гобәйдуллинның – «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча)»;

Р.К. Низамовның – «Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча)»;

Д.С. Романовның – «Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә җәмәгать контроле төбәк үзәге» ассоциациясе башкарма директоры (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын башкаручы** **А.В. Песошин**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ · АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 11 август
№ ПУ-635